# АКШ ХАТЫН-КЫЗЛАР ҖЫЕЛМА КОМАНДАСЫ ИРЕКЛЕ СТИЛЬ БЕЛӘН 4Х200 ЭСТАФЕТАДА АЛТЫН АЛДЫ

06.08.2015, 19:31

СПОРТ

Бу минутларда Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты кысаларында финал йөзеше тәмамланды. Ирекле стиль белән 4х200 эстафетасында дөньяның иң яхшы 8 хатын-кызлар командасы ярышты.

Иң көчлеләре АКШ йөзүче кызлары булып чыкты - алар 7:45.37 нәтиҗәсе күрсәтте. Алардан соң финишка 7:48.41 нәтиҗәсе белән Италия командасы килде. Призерлар өчлеген Кытай җыелма командасы тәгәлләде, алар дистанцияне 7:49.10 нәтиҗәсе белән йөзеп чыктылар.

ДЧ-2015. Йөзү

Хатын-кызлар. Эстафета, 4х200

1. АКШ - 7:45.37

2. Италия - 7:48.41

3. Кытай - 7:49.10

6 август. Казан. "Казан Арена"

Су спорт төрләре буенча 16 нчы ФИНА дөнья чемпионаты Оештыру комитеты матбугат хезмәте

ЯҢАЛЫКЛАР ТАСМАСЫН АЧАРГА